**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КРАСНОСЕЛЬСКИЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422700, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Биектау тимер юл станциясе поселогы, Совет урамы, 13

**СОВЕТ КРАСНОСЕЛЬСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422700, Республика Татарстан, Высокогорский район, п. ж/д ст. Высокая Гора, ул. Советская, 13

тел./факс 8(84365) 2-35-82,e-mail: Ksel.Vsg@tatar.ru

**КАРАР** **РЕШЕНИЕ**

**13 ноябрь 2023 ел** **№ 79**

## «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Красносельский авыл җирлеге советы Карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 нче елның 6 нчы октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге Советы

**КАРАР КЫЛДЫ:**

1. Биектау муниципаль районының Красносельский авыл җирлеге Советы «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2015 нче елның 15 нче октябрендәге 7 нче номерлы карарына (2018 нче елның 4 нче маендагы 81 нче номерлы, 2018 нче елның 13 нче сентябрендәге 91 нче номерлы, 2018 нче елның 21 нче декабрендәге 110 нчы номерлы, 2022 нче елның 25 нче ноябрендәге 59 нчы номерлы, 2023 нче елның 15 нче сентябрендәге 74 нче номерлы Совет карары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә::

3 нче пунктның 3.2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.2 «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында» Россия Федерациясе Президентының 2022 нче елның 21 нче сентябрендәге 647 нче номерлы Указы нигезендә, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Красносельский авыл җирлеге территориясендә мөлкәткә ия булган Россия Федерациясе гражданнарының физик затлар мөлкәтенә салым түләүдән азат итәргә.»

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында интернет челтәрендә түбәндәге адрес буенча: https://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында: http://pravo.tatarstan.ru урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

Совет Рәисе,
Красносельский авыл җирлеге Башлыгы Р.Ф. Хисаметдинов